وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلا تَفَرَّقُواْ

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

Дин вә Мәгыйшәт

№18 (161). 2 ноябрь 2012 / 18-зөлхиҗҗә-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

Казан губернасында муллалар ничек яшәгән? ▷2◁

Россиядә ислам икътисады – бу мифмы яки якын киләчәктәге чынбарлыкмы? ▷3◁



Казанда Барудиларны искә алдылар ▷4◁

КЫЛГАН ХАҖЛАРЫБЫЗ КАБУЛ БУЛСЫН!

Бу көннәрдә Татарстан хаҗилары туган якларына әйләнеп кайталар. Алар ерак изге сәфәрдән гомергә истә калырлык дулкынланулар, тирән кичерешләр аша рухи яктан баеп, ә иң мөһиме, меңләгән мөселман кардәшләребез белән бергә Аллаһы Тәгалә алдындагы бурычларын үтәп - хаҗ кылып кайталар. Коръәни-Кәримдә әлеге изге бурычыбыз турында ачык әйтелгән: "Анда ап-ачык аятьләр, Ибраһим баскан җир бар. Анда кергән кеше иминлектә булыр. Юлын тапкан (көче җиткән, хәленнән килгән) кешеләрне Аллаһ ризалыгы өчен анда (Хаҗга) барырга бурычлы итте. Берәрсе инкяр итә икән, Аллаһ аңа (һәм галәмдәге бернигә дә) мохтаҗ түгел" ("Әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)" сүрәсенең 97 нче аяте).

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән изге урынга барып, иманнарын ныгытып, рухи көч алып кайткан дин кардәшләрем өчен шатлыгымны белдерәсем килә. Барчабызга да Аллаһы Тәгалә хаҗ сәфәрләре кылырга насыйп әйләсен, хаҗиларга изге сәфәрләреике дөньяда да бәрәкәт китерсен. Кылган хаҗларыбыз кабул булсын!

Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ

ТОРМЫШ – иң катлаулы мәдрәсә

Кукмара мөселман мәдрәсәсе менә инде 14 ел дәвамында дин белеме, рухи тәрбия юнәлешендә изге-игелекле хезмәт башкара - район халкына аң-белем бирә. Дини гыйлемнең мөһимлеге, бүгенге җәмгыять кешеләренә ясаган йогынтысы турында, шулай ук яңа заманга хас булган кайбер мәсьәләләр һәм мәдрәсәнең быелгы эшчәнлеге хакында сораштыру нияте белән без әлеге уку йорты җитәкчесе Ришат Курамшин белән әңгәмә кордык. Шуны гәҗит укучыларга тәкъдим итәбез.

- Ришат хәзрәт, мәдрәсәнең эшли башлавыннан, ягъни 1998 елдан бирле Сез аның директоры вазифасын үтисез. Шушы 14 ел эчендә халыкның дин белән кызыксынуы арттымы, әллә кимедеме?

- Кызыксыну арта дип әйтергә нигез бар. Мин моны мәдрәсәгә укырга керүчеләр санына бәйләп кенә әйтмим. Җәмгыятьтә барган процессларга күз салып та, мондый нәтиҗәгә килеп була: мәгълүмат чараларында елдан-ел дин, ислам турында ешрак сөйләнелә, авылларда ничектер, зуррак бистә-шәһәр мәчетләрендә җомга намазына йөрүчеләрнең артуы да, урамда яулыклы хатын-кызларның күбәюе дә үзенә күрә уңай бер күрсәткеч булып тора. Гомумән, хәзер рухи тәрбия, җан, үлем, ахирәт мәсьәләләренә күп кеше битараф түгел. Безнең көннәрдә дин кануннары буенча яшәргә теләүче гаиләләр дә күбәйде, өлкәннәр дә, яшь барган саен, бу хакта ешрак уйлана башлый сыман.

- Быел җәен мөфтият җитәкчеләренә карата оештырылган һөҗүмнәр, башка шундыйрак вакыйгалар сагайтмыйча да калмый: болар дингә тискәре бер караш тудыра түгелме?

- Ә нигә әле бу вакыйгалар дингә тискәре караш тудырырга тиеш? Биредә дин әһелләре зыян күрүчеләр хисабында бит. Ә терактларны оештыручылар һәм башкаручылар, һичшиксез, мөселман түгел, чөнки моның ише гамәлләр Коръәннең хәрефенә дә, рухына да тәңгәл килми һәм берничек тә мөселманлыкның билгесе була алмый. Әлбәттә, шунысы аяныч: соңгы вакытта җинаять юлына баскан кайбер затлар явыз гамәлләрен ислам, Коръән белән бәйләмәкче була, әмма бу - ялган. Әлбәттә, сарык тиресенә төренгән бүреләрнең кыланмышлары ислам дине белән таныш булмаган кешеләрдә ниндидер шик уятырга мөмкин, әмма ахыр чиктә хакыйкать барыбер билгеле була. Пычракка атылган алтын үз кыйммәтен югалтмаган кебек, Ислам үзенең актуальлеген, әһәмиятен һәм кыйммәтен беркайчан да югалтмаячак.

- Шулай да бүген үзләрен мөселман дип атаучы яшьләр арасында экстремистик дип әйтәсем килми, әмма кызурак холыклы, радикаль карашлырак егетләр бар. Аларга нәрсә әйтер идегез?

- Адәм баласы нинди дә булса эшчәнлек алып барган һәр өлкәдә төрле холыклы кешеләр бар, бу - табигый нәрсә. Тәкәббер, үҗәт, кызурак мөселманнарга Мөхәммәд пәйгамбәр миссиясенең төп максатын искә төшерү файдалы булыр, дип уйлыйм. Ә Пәйгамбәребез (сгв): "Мин гүзәл әхлак урнаштырыр өчен җибәрелдем", - дип белдергән кешеләргә. Холкың усал, сүз-гамәлләрең тупас икән, димәк, син пәйгамбәреңне үрнәк итеп тотмыйсың. Ә кешеләргә зыян китерү, бигрәк тә җинаять юлына басу - бу инде үз эченә "тынычлык", "иминлек" дигән мәгънәне алган "ислам" төшенчәсенә туры килми. "Башкаларга кулы һәм теле белән зарар китермәгән кеше генә чын мөселман була ала", - дигән Мөхәммәд галәйһиссәләм. Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез (сгв) болай ди: "Чын мөэмин бал корты кебек: ул фәкать яхшы нигъмәтләр белән ризыклана һәм яхшы нигъмәтне генә булдыра, ә чәчәккә кунганда аны сындырмый, аңа бернинди зыян салмый".

- Соңгы вакытта "традицион ислам" дигән гыйбарә еш телгә алына, ләкин күпләр аның төгәл мәгънәсен белми.

- Әйе, беренче карашка сәеррәк килеп чыга кебек. Бездән дә: "Традицион ислам бар икән, традицион булмаганы да бармыни?" - дип сорыйлар кайчакта. Әлбәттә, ислам дине бер, әмма кешеләр аны төрлечә аңларга мөмкин. Бүген ислам динен үзенчә аңлаган, аның асылын рәхимсезлек, агрессивлык дип, бигрәк тә дин белән бәйләп бер гаепсез кешеләрне үтерергә, шартлатырга ярый дип күз алдына китерүчеләрнең пәйда булуы безне гасырлар дәвамында сакланып килгән, мәрхәмәтлелеккә, гомумкешелек кыйммәтләргә нигезләнгән ислам традицияләрен тагын бер кат искә төшерергә мәҗбүр итә.

"Традицион" ислам дигәндә, мәзһәб мәсьәләсен дә исәпкә алырга кирәктер. Мәзһәб ул - динебезнең канун-кагыйдәләрен аңлатучы хокукый юнәлеш. 922 елда бабаларыбыз рәсми рәвештә Исламны кабул иттеләр һәм шул вакыттан бирле татар мөселманнары Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча гамәл кылганнар, бу юнәлеш татар халкы рухи тормышында нигез ролен үтәде. Әмма хәзер шушы нигезне үзгәртергә теләүчеләр барлыкка килде. Тарихи мәгънәдә сыналган, гасырлар буена ныгыган нигезне алыштыруда хаҗәт бармы соң? Әгәр агач тамырын икенче тамырга алыштырам дип чабып алсаң, ул агач үләчәк. Хәнәфи мәзһәбе бүген татарлар өчен шул агач тамыры кебек инде: аны алыштырырга маташу ислам "агачы-бызны" корытуга, юк итүгә генә китерәчәк. Кызганычка, кайбер яшьләр моңы аңлап бетерми, чит илләрдә, бигрәк тә Гарәбстанда булган вазгыятьне бездәге вазгыять белән тиңли.

Традицион ислам төшенчәсен аңлатканда милләт, милли үзенчәлек дигән мәсьәләне дә искә алмыйча булмыйдыр. Әлбәттә, беркем дә "Аллаһы Тәгалә һәр халык өчен аерым ислам дине биргән" дип әйтми. Ләкин "диндә милләт юк" дип әйтү Аллаһның "Мин сезне төрле халыклар итеп яраттым" дигән аятенә каршы килә (Коръәндәге "Бүлмәләр" сүрәсенең 13 нче аяте).

Шулай итеп, хәнәфи мәзһәбе буенча гамәл-гыйбадәт кылу, үзебезнең милли гореф-гадәтләреебезне саклау - татарларның мең елдан артык чорны үз эченә алган традициясе ул. Хәзерге вакытта "диндә милләт тә юк, мәзһәб тә юк" дип, шушы традициябезне юк

(Ахыры 4 нче биттә.)

ЯҢАЛЫКЛАР

ТОТКЫННАР ӨЧЕН КОРБАН БӘЙРӘМЕ ЧАРАЛАРЫ ОЕШТЫРЫЛДЫ

Россиянең Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә караган төзәтү учреждениләре 120 мең сумлык азык-төлек белән тәэмин ителде. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Корбан бәйрәме вакытында - 18, башка мөселманнар, тоткыннарның якыннары 15 корбанлык сарык бирде. 20 октябрьдән алып 29 октябрьгә кадәр нәзарәтнең РФ Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән элемтәләрне координацияләү бүлеге мөдире Айрат Зарипов һәм нәзарәтнең башка хезмәткәрләре 18 тапкыр төзәтү учреждениләренә хәләл ризык илтте.

Шулай ук нәзарәт төрмәләрдә Корбан бәйрәмен үткәрү өчен ризык алырга 30 мең сум акча бүлеп бирде. Хөкем ителгәннәрнең туганнары һәм җирлектәге мөселманнар тарафыннан 90 мең сум күләмендә ярдәм күрсәтелде.

Идарә учреждениләрендәге барлык мәчетләрдә, намаз бүлмәләрендә бәйрәм намазлары укылды, аларда барлыгы Ислам динен тотучы җиде йөзләп хөкем ителгән кеше катнашты. Барлыгы 3 мең пенсионер, инвалид, авырулар һәм башка тоткыннарга бәйрәм сые әзерләнде.

Бәйрәм чаралары Россиянең Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе житәкчелеге белән килешеп оештырылды.

АРЧАДА МӘЧЕТЛӘР АРТА

26 октябрьдә Арча шәһәренең Көнчыгыш бистәсендә яңа мәчеткә нигез салынган. Район имам-мөхтәсибе Раил хәзрәт Гыйләҗев билгеләп үткәнчә, бүгенге көндә Арча шәһәрендә өч мәчет эшли, тагын бер мәчеткә манара куясы һәм эчке төзелеш эшләрен генә төгәллисе бар. Нигез салынган яңа мәчет - шәһәрдәге бишенче мәчет булачак. "Төзелеш эшләре халык ярдәме белән башкарыла. Һәр мәчеткә дә халык агылып йөри", - дип билгеләп үтте хәзрәт.

"ВӘГАЗЬ" КИЧӘЛӘРЕ УЗДЫРЫЛАЧАК

Һәр атнаның дүшәмбе көнендә башкалабызның "Шәрык" клубында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Алтын урта" мөселман яшьләре оешмасы әгъзалары белән берлектә "Вәгазь" кичәсе уздырылачак. Татар яшьләре клубында "Вәгазь" кичәсе мөселманнарга, шулай ук дин белән кызыксынучыларга үзара аралашу һәм аларга дин, әдәп-әхлак турында вәгазләр тыңлау мөмкинлеге тудыру максатыннан үткәрелә. Кичәне "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкерте Илнур Әсхәтов оештыра, вәгазләр укырга дин әһелләре чакырыла. Чара кичке сәгать алтыда (18.00) башлана.

Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды

ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙЙК!

1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.

КАЗАН ГУБЕРНАСЫНДА МУЛЛАЛАР НИЧЕК ЯШӘГӘН?

Әлеге мәкаләдә сүз XIX йөз ахыры – XX йөз башында Казан губернасындагы татар муллаларының мәхәллә халкы белән үзара мөнәсәбәтләре турында барачак.

«Хөсәения» мәдрәсәсе идарәчеләре һәм имтиханда катнашкан казыйлар.

Казан губернасында муллалар татар җәмгыятенең, халыкның иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни тормышында мөһим социаль роль уйнаган алдынгы катламы булган. Алар җәмгыять алдында мөһим эшләр башкарганнар. Мәчеттә дини гыйбадәтләрне җитәкләү, төрле дини йолаларны башкару, гаилә-никах мөнәсәбәтләрен көйләү, граждан актларын теркәү, мирас бүлү, төрле белешмәләр төзеп бирү, мәхәлләдәге балаларны укыту, әдәп-әхлакны күзәтеп тору, миссионерлык эше, мәхәллә халкына хөкүмәтнең мөһим фәрманнарын, күрсәтмәләрен җиткерү һ. б. бик күп эшләр алар өстендә булган.

Дин эшлеклеләренең җәмгыяттәге эшчәнлеге халыкның яшәешенә зур йогынты ясаган. Тормышның бар мөһим моментларында да, халык үзенең муллаларына мөрәҗәгать иткән. Муллалар дингә хезмәт итеп, гаделлек һәм гыйлемлелекне пропагандалап кына калмаганнар, ә үз халкының рухи лидерлары булып мәдәниятне һәм традицияләрне саклаганнар. Мәсәлән, билгеле этнограф Я.Д. Коблов болай дип яза: “Мәхәлләдәге халык мулланы олылап һәм хөрмәт итеп кенә калмый, ә билгеле бер дәрәҗәдә курка да. Шундый күренешне күз алдына китерик. Урамда яшьләр төркеме төрле уеннар белән күңел ача. Беркем белән дә тыелмаган бу яшь кешеләр, үзләрен артык иркен тоталар, кычкырышалар, җыр-тавышлар өзелеп тормый. Бу күңел ачуның азагы булмас кебек тоела. Һәм менә, мулла өеннән чыга. Ашыкмый гына, ул үзенең җитди һәм олпат кыяфәте белән урам буенча бара. Урамдагы бу тавыш-кычкырышның бетүенә аның менә шул бер күренүе дә җитә. Бу яшьләрнең бар шаяннары, бар шуклары, һәм дә иң кыюлары да, кем кая туры килә, шунда качып бетәләр. Гомумән, мөселман җәмгыятендә ныклы дисциплина саклана, ул дисциплина аларда кече вакытларында ук, гаилә һәм мәктәпләрдә тәрбияләнә”.

Һәрбер мулла үз мәхәлләсендәге халыкның әхлакый тәртибен ныклап күзәтеп торырга, җәмгыятьтә бозыклыкка китерүче бар күренешләрне дә тамырыннан ук юк итәргә тырышырга тиеш дип каралган. Әйтик, муллалар аеруча үз мәхәлләләрендә эчкечелек белән нык көрәшәләр. Диннең спиртлы һәм башка исерткеч эчемлекләрне тыюына да карамасан, кайбер татарлар, аеруча шәһәрдәге эшче сыйныфтагы һәм рус авыллары янында урнашкан авылларда яшәгән татарлар, еш кына качып-посып эчкәли торган булганнар. Әгәр дә, мәхәлләдә эчеп алган берәрсен күрсәләр, аны шунда ук тотып алып муллага алып килгәннәр. Ә мулла исә, бер дә көчен кызганмый, аны таягы белән тукмый торган булган. Базарлы авылда – Әтнәдә, муллаларның таләбе белән, бу кибетләрдән аз булмаган табыш алучы аларның хуҗаларының нык каршы килүенә дә карамастан, шәраб һәм сыра сату кибетләре ябыла. Ә бу авылга базар көннәрендә татарлар гына түгел, руслар да килгән.

Муллаларны үз вазифаларын тырышып башкарганнары өчен берәү дә гаепләмәгән. Киресенчә, мондый гамәлләрне халык нык хуплаган. Я.Д. Коблов язуынча, “мулла ниндидер тәртип бозучыны яки җинаять кылучыны, мәсәлән, аракы эчүчене яки урлашып тотылучыны, җәзага тарта башлавы гына була, законның изгелегенә тырышлык куючы башкалар, аның бу эшен дәвамлы итеп, төгәлләп тә куя торган булганнар. Мөселман авылында исерек кешене очратуы кыен булуы шуңа күрә бер дә гаҗәп хәл түгел”.

Рухи яктан мулла мәхәлләнең башка мөселманнарыннан артык аерылып тормаган. Әлбәттә, дин тәгәлиматын яхшырак белгән, әмма аның сүз һәм фикерләре, башкалар белән бер үк төрле белем һәм тәрбия алулары мәхәлләнең башка кешеләренеке кебек үк булган. Мәхәлләдәге мөселман кыскача рәвештә иман нигезләрен белгән, ә мулла исә – аны җентекләп өйрәнгән. Алар арасындагы бар аерма шунда. Мәнфәгатьләрнең, ышануларның, карашларның берлеге мулланы мәхәллә халкы белән берләштергән. Мәхәлләгә җитәкче мулла, күпчелек очракларда, әлбәттә, ул мәхәллә белән үзе теләгән юнәлештә җитәкчелек итә алган. Мулланы алдау яки нәрсәне дә булса аннан яшереп алып калу – кыен эш булган. Ул мәхәллә халкының бар гамәлләрен генә түгел, ә уй-фикерләрен дә белеп торган, чөнки, ул да алар яшәгән проблемалар белән яшәгән, һәм шуңа да аларга тиешле йогынты ясый алган. Ә икенче яктан, халык муллага чит кеше итеп карамаган һәм дә аның абруена карусыз буйсынган. Бу җәһәттән, татар муллалары, рус православ дин әһелләре белән чагыштырган вакытта, шактый өстенлеккә ия. Шул ук вакытта, мулланың һәр адымы, һәр әйткән сүзе, аның бар таныш-лары мәхәллә мөселманнарына билгеле булган. Дин кагыйдәләрен яки традицион йолаларны бозу дип исәпләнгән гамәлләре ачыкланган муллага бер дә җиңелгә туры килмәгән. Мулла, алар фикеренчә, дин һәм закон вәкиле. Һәм шуңа да, ул калганнарга үрнәк булырга һәм үз вазифасы биеклегендә торырга тиеш булган, дип яза Я.Коблов.

Имам үз вазифаларын тиешенчә башкармаса, яки, үзенең җәмгыятьтәге югары статусын дискредитацияләсә, мәхәллә мөселманнары бу дин әһелен вазифаларыннан азат итеп, икенчесен сайлап куярга хокуклы. Мондый хәлләр, кагыйдә буларак, мулла шәригать кануннарын яки гражданнар законнарын бозган очракта, яисә, мулланың эчәргә яратуы ачыкланганда эшләнгән. Андый дин эшлеклеләре еш кына рисвай ителеп куылганнар. Шундый бер очрак, мәсәлән, Тәтеш өязендәге Шәпкә авылы (хәзерге Татарстанның Кама Тамагы районында. – **ред.**) мулласы Мөхәммәтсабир Мәһәдиев белән 1893 елны килеп чыккан. Аны “айнык тормыш алып бармавы өчен” эшеннән чыгарганнар. Аның урынына халык шул ук өязнең Әҗем-Күрлебаш авылы крестьяны Зәһретдин Садретдиновны (1865 елда туган) сайлап куя. Мөхәммәтсабир хәзрәтнең күп тапкырлар акланырга һәм вазифасына кире кайтырга тырышулары уңышсыз төгәлләнгән. 1904 елның маенда Тәтеш өязендәге Әхмәтле авылының (хәзерге Ульян өлкәсенең Николаевка районында. – **ред.**) Икенче җәмигъ мәчет имамы Насретдин Арсланов “мөселман диненә каршы килә торган төрле эшләре өчен” вазифаларыннан азат ителә. 1889 елның августында мәхәллә халкы хөкеме белән Казан өязе Симетбаш авылы (хәзерге Татарстанның Арча районында. – **ред.**) мулласы Абдулла Камалетдинов (Искәндәров) “үзенең хезмәт вазифаларын тиешенчә башкармаганы һәм начар тәртибе өчен” эшеннән алына.

Бу сәбәпләрдән тыш, халык гозере белән муллалар “гыйбадәт кылган вакытта һәм дини таләпләрне үтәгәндә җибәрелгән кимчелекләре”, “мәчеттә хезмәт куюга зыян китереп, коммерция белән шөгыльләнгәннәре”, “үзбелдекләнеп эштә булмаулары һәм яман тәртипләре” өчен дә үз вазифаларын югалткан-нар.

Мулла белән мәхәллә халкы арасында урнашкан конструктив диалог, күп кенә авыр хәлләрдән чыгарга, җәмгыятьнең мөһим проблемаларын хәл итәргә мөмкинлек биргән.

Тормышта авылдашлары муллага гаилә мәсьәләләре буенча гына түгел, ә башка бәхәсле проблемалар буенча да, мәсәлән, урлашкан өчен, саулыкка зыян китергән өчен гаепләнүчегә җәза билгеләргә һәм башка проблемаларны чишәр өчен дә мөрәҗәгать иткәннәр. Татар авылында мәхкәмә шулай барган. Зыян күрүче килеп чыккан хәл турында авыл старостасы белән муллага хәбәр иткән. Аннан соң староста җыелыш көне билгеләгән, халыкны үткәрелә торган чаралар белән таныштырган һәм җыелышта карала торган эшне алып бару өчен муллаы чакырган. Хөкем чыгарган вакытта мулла гади хокук нормаларына һәм шәригать кануннарына таянган. Җибәрелгән гаеп эшләр өчен еш кына тән җәзасы кулланылган, аны мулла сайлап алган авыл кешеләре башкарган. Җәза бирү, гадәттә, шунда ук, халык күп җыелган урында башкарылган.

Дин әһелләре халыкның әхлак тәртибен аеруча ныклап күзәтеп торганнар. Мәсәлән, шәригать азартлы уеннар уйнауны тыйган. Әгәр кемнең дә булса азартлы уеннар уйнавын белсәләр, аны муллага алып барганнар, мулла аңа үгетнәсыйхәт биргән. Әгәр дә инде бу кеше мондый гаебе белән тагын бер тапкыр эләгеп тотылган икән, аны я чыбык белән сугып, җәзага тартканнар яки өч көнгә кулга алып, ябып торганнар. 1875 елны исә Диния нәзарәте “Бар муллаларга да, үз мәхәлләләрендәге кешеләрне тән һәм башка төрле җәзаләрга тарту һәм, гомумән, үзләренә үзләре өчен хас булмаган хөкемдарлар ролен алу катгый тыела”, – дип фәрман чыгара.

Мәчетләр җәмәгать намазлары урыны булганлыктан, аларга тиешле дәрәҗәдә игътибар күрсәтелергә, хөрмәт ителергә һәм тәртиптә тотылырга тиеш булганнар. Шуның өчен муллалар авыл халкын аларны тәртиптә тотарга җитәрлек дәрәҗәдә акчалар табарга күндергәннәр. Ә мәчетләрне тоту өчен шактый гына эшләр башкарырга кирәк: вакытында ремонт ясарга, мәчетне җылыту өчен җитәрлек дәрәҗәдә утын әзерләп куярга, яктырту өчен шәм һәм керосин запаслары булдырырга, мич һәм төтен чыгару морҗаларын төзек хәлдә тотарга һ. б.

Мөселман дин эшлеклеләренең матди яктан яхшы тәэмин ителгән булуы, аларның үз хезмәтләрен башкаруларында һәм халык белән - мөнәсәбәтләрендә мөһим аспектка әверелгән. Керемнәренең төп чыганагы – халыктан җыелган иганәләр. Алар акчалата продуктлар, башка әйберләр бирү формасында да булган яки халык үзе килеп эшләп тә ярдәм иткән. Үз хуҗалыклары да (игенчелек, терлекчелек, бакчачылык), төрле һөнәрчелек (умартачылык, табиблык, тегүчелек һ. б.) һәм сәүдә дә дин эшлекләре кеременең шактый өлешен тәшкил иткән. Нигездә, алар халыктан әллә ни аерылып тормаганнар, ләкин татар мәхәлләләрендә үзләренә йөкләнгән мөһим социаль вазифалар башкарулары һәм үз шәхси керемнәре аларны җәмгыятьтә башкалардан аерып күрсәткән һәм матди яктан тәэмин ителгәннәр рәтенә куйган.

Мөселман дин эшлеклеләренең халык белән мөнәсәбәтләре арасында тагын бер мөһим аспектлардан суфичылыкны – тәсаувүфне (башкача: кешенең яшеренгән, эчке күңел кимчелекләре белән көрәшкә һәм шәхесне рухи тәрбияләүгә юнәлтелгән Исламдагы дини тәгәлимат һәм практика) билгеләп китәргә кирәк. Күпчелек татар муллалары тарикатьтә булганнар яки билгеле шәех-ишаннарның укучылары (дини дәвамчылары) булып торганнар. XX йөзгә кадәр бар татар мөфтиләре дә билгеле шәехләрнең мөридләре булганнар. Бу – очраклы хәл түгел: тәсаувүфтә тәрбия алу – татар дин эшлеклесе булып китү өчен зарури элемент булып саналган. Ул вакытларда җәмгыятьтә югары баскычта тору, дин өлкәсендә яңа идеяләр тәкъдим итү, ә кайвакытта исә, карьера баскычы буенча югарырак күтәрелү дә Идел буе мөселманнарында, шул ук вакытта, Урта Азиядә дә суфичылык тарафдары булу-булмауга бәйле булырга мөмкин. Татар ишаннарының эшчәнлеге, Исламның, гыйлемлелекнең, укымышлылыкның тагын да киңрәк таралуына, халыкның тәрбияле булуын арттырырга ярдәм иткән, татар милли яңарышына күп өлеш керткән. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар муллаларын һәм галимнәрен җәдитчеләр (реформа тарафдарлары) һәм кадимчеләргә (реформаларга каршы булучылар) бүлгән вакытта, без, бары тик кадимчеләр генә суфичылык тарафдарлары булган дип әйтә алмыйбыз. Җәдитчелекнең күп кенә вәкилләре нәкышбәнди мөридләре һәм ишаннары булган. Ул чорларның рәсми дини эшлеклелеккә карата оппозициядә торучы дип исәпләнүче бар татар мәгърифәтчеләре һәм фикер ияләре дә нәкшибәндия тарикате белән мөнәсәбәттә торганнар.

XIX гасыр һәм XX гасыр башларында Идел-Урал төбәгендә бер үк вакытта мәхәллә муллалары, мәдрәсә җитәкчеләре вазифаларын да башкаручы, җәмгыятьтә зур дәрәҗәгә ия бик күп суфи шәехләре яшәгән. Шулар арасында: Хәбибулла Оруви, Гали Түнтәри, Алишевлар династиясе (Кизләү ишаннары), Тукаевлар (Эстәрлебаш ишаннары), Закир ишан әл-Чистави (Мөхәммәдзакир Камалов), Зәйнулла ишан Рәсүли, Галимҗан Баруди, Әхмәд Кизләви, Мәхмүд Кизләви, Хәсәнҗан Кизләви, Фәхретдин Нурлати, Нургали Хәсән әл-Буави, Шәрәфетдин Суксуви, Абдуллатиф бине Яһүдә, Әхмәдсафа бине Аббас, Әхмәдлатыйф бине Абдуллатыйф, Мөхәммәд бине Мөхәммәдхәсән әл-Урмати, Нуретдин бине Мифтахетдин, Шаһиәхмәд бине Аббас, Мөхәммәдхафиз әл-Казани, Мөхәммәд Шакир (Сембер), Хәйрулла Алмати һәм башка бик күпләр. Табигый, мәхәллә мәчетенең җитәкчесе шәех яки ишан булса, аның халыкка йогынтысы да күпкә зуррак һәм абруйлырак саналган.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: XIX йөз ахыры – XX йөз башында татар муллаларының мәхәлләләрдә дини-әхлакый йогынтысы гаять зур булган. Бу мулланың шәхси рухи сыйфатларына, интеллектуаль сәләтләренә, аның тәртибенә, тормыш алып бару рәвешенә бәйле. Әгәр дә мулла үз вазифаларын тырышып үтәсә, үрнәк тормыш алып барса, мәчеткә төгәл вакытта, намазларны калдырмыйча йөрсә, мәхәллә халкының тәртибен игътибар белән карап торса, аларны гаепле эшләре өчен гадел хөкем итсә, гомумән, мөселманнар һәм гражданнар законнарын саклауда тиешле хезмәт һәм тырышлык күрсәтсә, ул мәхәллә халкы алдында зур абруйга ия булган һәм мәхәлләнең социаль-мәдәни тормышында барысы тарафыннан да танылган җитәкче булып исәпләнгән. Юкка гына халкыбыз: “Мулласы нинди, мәхәлләсе шундый”, – димәгән бит.

Рәшид МАЛИКОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Буа мәдрәсәсе директоры

Россиядә ислам икътисады – бу мифмы яки якын киләчәктәге чынбарлыкмы?

Бүгенге көндә Россиядә ислам икътисадын үстерү, икътисадтагы үзара мөнәсәтләрдә ислам принципларын кертү турындагы фикерләр - шактый еш ишетелә. Моны яклап күп дәлилләр китерелә, мөселман халкы саны Россиядә тиз артуы турындагы дәлилләр дә алар арасында соңгыларыннан түгел.

Чынлап та, илнең демократик юл белән үсә торган булуына аның җирле халыкның шактый өлешен тәшкил иткән мөселман халкына үзләренчә тормыш алып барырга мөмкинлекләр тудыру да керә. Ә бу халыкларның тормыш алып бару нигезләре нәкъ менә ислам йогынтысында формалашкан, һәм дә, андый формалашу тыныч юл белән, бернинди чикләүләрсез барган. Шуңа да без якын елларда турыдан-туры ислам факторы белән билгеләнүче кайбер регионнарның, тармакларның, эшчәнлекнең башка өлкәләренең бик тиз үсеше шаһитлары булырга мөмкинбез. Мөселманнарның икътисадта фикер йөртүләренең, ислам бизнес-этикасы үзенчәлекләрен испкә алу - мөселман һәм мөселман булмаган халыкларның үзара тату, уңайлы шартларда яшәвенә, аларның интеграциясенә аз югалтулар белән ирешергә мөмкинлек бирәчәк.

Икътисади тормышка ислам принципларын кертү һәм Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын яулау тулы бер этаплар рәтен үтүне таләп итә. Алар арасында - бизнес алып барудагы ислам ысулларына өйрәтү дә, мөселман коммерция структураларында эшләргә сәләтле яллаулы хезмәткәрләр әзерләү дә, бизнес алып бару стандартларын эшләү дә, хәләл товарлар өчен стандарт таләпләре эшләп чыгару да бар. Зәкят җыю һәм аны нәтиҗәле куллану системасын эшләү һәм аны эшкә кертеп җибәрү дә, вакыфлар (фондлар) системасын үстерү дә, хаҗ кылу өчен акча туплау системасын эшләү дә, ислам банклары һәм ислам хәвефсезлек вакыфларын ачу да, икътисади эшчәнлекнең шәригать нормаларына туры килүен күзәтеп торучы шәригать шураларының күп баскычлы системасын булдыру да шул урында тора. Мөселман бизнес берлегенең эшчәнлек әйләнеше кагыйдәләрен эшләп чыгаруы күп вакыт алырга мөмкин. Шул исәптән, закон системасын модернизацияләү дә. Ләкин моның өчен мөселман бизнес берлеге берләшергә, үзләренең уртак икътисади мәнфәгатьләрен аңларга, аларны федераль дәрәҗәдә әйтә алырга тиеш.

Ләкин, ислам икътисады принципларының илебездә эшчәнлек алып бару практикасына кереп китү процессының уңышлы булуына бу гына гарантия биреп бетерми әле. Әлбәттә, һичшиксез, бизнес-берлекнең үз эчендә дә дискуссияләр һәм кайбер каршылыклар килеп чыгачак.

Иң соңгы дәвердә, ислам икътисады, Россиядә, шактый сандагы башка илләрдән, хәтта моннан берничә йөз ел элек аларда бернинди мөселман халкы булмаган илләрдән дә, мәсәлән, Франция белән Бөекбританиядән дә соңрак үсә башлады. Икътисади тормышның ислам формалары, хәтта аларда да нормага әйләнеп бара. Без БДБ илләренең шактыеннан, мәсәлән, Казакъстаннан да калышып барабыз. Шуңа да, ислам принципларын Россия икътисадына кертү җитәрлек санда чит тел (гарәп, фарсы, төрек, инглиз h. б.) белүче кешеләрнең булуына турыдан-туры бәйле. Шул ук вакытта, берничә чит тел һәм башка илләрдә ислам икътисадын кертүдәге проблемаларны нинди ысуллар белән уңышлы чишкән икәннәрен белүче эшкуарларның билгеле бер катламы булу да, шулай ук, гарантия бирә алмый.

Россиягә ислам икътисады принципларын кертүдәге төп проблема - җәмгыятьнең аны ничек итеп кабул итүе мәсьәләсе. Ислам бизнес-берлеге икътисад мөнәсәбәтләренең ислам моделе өстенлекләрен үзенең көндәлек хезмәте белән исбат итә алырмы? Үз эшчәнлеген озак вакытлар конструктив үсешкә, инновацияләр кертүгә, югары технологик сәнәгать тармакларын үстерүгә юнәлтелгән булуын Россия халкына исбат итә алырмы, әллә барысы тик табигый байлыклар чыгаруга гына юнәлеш тотармы? Россия ислам бизнес берлеге прогрессив хезмәт мөнәсәбәтләре төзи алырмы, үз хезмәткәрләренең югары квалификацияләрен, аларның намуслы хезмәт итәргә омтылуларын дәртләндерерме, социаль яклауның эффектив системасын төзи алырмы?

Галим ВАХИТОВ,
икътисад фәннәре кандидаты,
Россия ислам университетының
Ислам икътисады һәм идарәсе
кафедрасы мөдире

Аллаһның рәхмәтләре булсын!

Мөселманнарның иң зур һәм мөбарәк бәйрәмнәренең берсе - Корбан гаете. Корбан чалу Аллаһы Тәгалә тарафыннан Аңа ел буена биргән нигъмәтләренә шөкер итәр өчен әмер ителгән. Шушы бәйрәм уңаеннан, 30 октябрьдә Мамадыш шәһәре мәдрәсәсендә, бәйрәмне олылап, Әхмәд Ясәви мәчете Нурислам Газизов җитәкчелегендә Корбан бәйрәме үткәрелде.

Уку йорты эчендә бәйрәм өйлә намазыннан соң башланды. Анда әбиләр, бабайлар, апалар, абыйлар, балалар бик күп иде. Мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин бәйрәмне "Фатиха" сүрәсе һәм вәгазь белән ачып җибәрде. Ул көчле тавышы, мәкам белән сүрәне көйләгәндә хәзрәтнең һәрбер сүзен йөрәгем аша уздырдым. "Бар бит гыйлемле хәзрәтләребез, Аллага шөкер!" - дип уйлап куйдым. Районыбыз имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миннегалиев: "Кешеләр алдында дәрәҗәбез булсын, үзебезнең хезмәт сөючәнлегебез, чисталыгыбыз, пакьлегебез, намусыбыз, тырышлыгыбыз белән үрнәк булып торыйк. Дөньялык өчен генә түгел, ахирәтебез өчен дә гамәлләребез булсын. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршына үзебез белән алып бара торган намазларыбыз, уразаларыбыз, зәкятләребез, корбаннарыбыз да булсын", - диде. Әхмәд Ясәви мәчете имам-хатыйбы Нурислам хәзрәт Коръән сүрәләре укыды. Бәйрәм чәй табыны артында дәвам итте. Бу бөек бәйрәмнең эчтәлеге нәкъ менә кешеләр мәнфәгатен кайгырту, аларны ярату һәм ярдәм кулы сузарга әзер булуга нигезләнгән. Изге Корбан бәйрәме көнендә кылган догаларыбыз кабул булсын, изге ниятләребез һәм якты хыялларыбыз тормышка ашсын. Йортларыбызга, мәдрәсәбезгә бәрәкәт, күңелләребезгә - иман нуры, бу бәйрәмне оештырган абыстайларыбызга, хәзрәтләребезгә иминлек, тынычлык һәм мәхәббәт хисләре иңсен. Тәкәбберлекне ташлап, ата-анага, туганнарга һәм бөтен җан ияләренә ихтирамлы булып, бәхиллекләрен сорап, хәер-догаларын алырга тырышырга кирәк. Барыбыз да изгелек эшләргә ашыгыйк! Бу бәйрәмне оештырган Әхмәд Ясәви мәчете абыстае Рәсимә абыстай Гайнетдиновага, Нурислам хәзрәт Газизовка, мәхәллә халкына Аллаһның рәхмәтләре булсын!

Фирая МИНГАЛИЕВА,
Мамадыш шәһәре

Корбан бәйрәме тагын кайда-ничек узган?

ЧАЛЛЫ

Корбан бәйрәменең беренче көнендә биредә 900 ләп корбан чалынган. Өч көнгә якынча - 1500. Мәчет тирәләрендә корбан чалу рөхсәт ителмәгән. Корбан чалу Сидоровка бистәсендә махсус әзерләнгән урында башкарылган. Рамазан, Туфан, ГЭС мәчетләрендә мохтаҗларга хәйрия ашлары үткәрелгән. 27 октябрьдә Нур-Ихлас мәчетендә балалар өчен бәйрәм оештырылган.

Әбүзәр мәчете 26 октябрьдә "Мирас" мөселман мәктәбендә бәйрәм ашы үткәргән. Анда укучылар һәм аларның ата-аналары, җәмгысы 240 кеше катнашкан. 25 октябрьдә әлеге мәчетнең имам-хатыйбы Гали хәзрәт Баһаутдинов "Снежок" ял базасында да Корбан ашы үткәргән. 27 октябрьдә исә ГЭС мәчетендә кече яшьтәге мәктәп балалары мәҗлескә җыелган. 28 октябрьдә Тукай районы хакимияте ашханәсендә балалар һәм картлар өчен чираттагы хәйрия ашы уздырылган.

ӘЛМӘТ

Биредә дә корбан чалу өчен алдан махсус мәйданчыклар булдырганнар. Бәйрәмне тиешле дәрәҗәдә үткәрүгә район хакимияте һәм "Татнефть" җитәкчеләре зур өлеш керткән.

Кичен Р.Фәхреддин исемендәге мәдрәсә шәкертләре өчен махсус мәҗлес оештырылган. Мәдрәсәнең директоры Рафикъ хәзрәт һәм мәдрәсә мөгаллимнәре шәкертләрне әлеге олуг бәйрәм белән котлаган. Корбан бәйрәмен үткәрү өчен махсус программа әзерләнгән: төрле спорт ярышлары, бәйгеләр, викториналар оештырылган.

30 октябрь көнне Габдрахман авылында, 31 октябрьдә Әлмәтнең Үзәк мәчетендә зур мәҗлес үткәрелгән.

Идел буенда ислам сәнгатенең башлангыч чоры үзенчәлекләре

(Ахыры. Башы газетабызның 26 октябрь (№17) санында.)

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, шартлылык күп урында борынгы төрки күчмә сәнгатенең стиль үзенчәлекләре белән билгеләнә. Зооморф образлары реалистик үзләштерү йөртүче (әлбәттә, аларда булган кайбер декоратив стильләшү элементларын исәпкә алып) Көнбатышның игенчелек цивилизацияләренең антик һәм эллин сәнгатеннән аермалы буларак, болгарларның күчмә бабаларындагы "җанвар стиле", гомумән, зооморф образлар, һәрвакыт яссы һәм график формада, шартлы, схематик рәвештә сурәтләнгәннәр. Мондый сурәт ясау күчмә дала мәдәнияте өчен хас булган һәм ул болгар осталары сәнгатендәге сурәтләү принципларында да сакланган.

Шунысы игътибарга лаек, болгар гамәли сәнгатенең орнамент мотивлары, аларны үзләштерү характеры, сәнгать теленең вариантлылыгы белән композициянең ирекле чишелешенә караганда, Шәрыкның классик илләрендәге мөселман осталары үтәргә мәҗбүр булган профессиональ таләпләр һәм иҗат итү кануннарының катгый рамкалары белән артык кысылган булмаганнар. Бу болгар сәнгатенең һәм орнамент теленең, сурәт төшерү, колористик мәгънәдә генә дә түгел, ә иҗат итү мәгънәсендә дә, стиль үзенчәлекләре турында да әйтергә мөмкинлек бирә. Бизәкләрне һәм сурәтләрне куллануда иҗат ирекле халык сәнгате системасына хас. Бу - болгар сәнгать осталыгының тере халык традицияләре белән булган тирән бәйлелеген күрсәтә, аның X-XI гасырларда "җанвар стиле"нә алмашка килгән зооморф бизәкләрне үзләштерүдә һәм мөселман сәнгатендә өстенлек алган чәчәкүсемлек орнаментын саклануда күзәтелә. Шәрык орнаменты белән булган күп кенә уртаклык күренешләренә дә карамастан, болгар бизәк төшерү орнаменты үзенең оригинальлеген саклап кала. Ул чыгышын борынгы төрки мәдәният чорларына барып тоташкан архаик мотивлардан ала. Борынгы төрки мәдәният Көньяк Себер һәм Үзәк Азия сәнгатеннән башланып киткән һәм б. э. кадәрге Таулы Алтай кабиләләренең сәнгате белән ныклы бәйләнештә булган (Пазырык курганнары), тарихта урынын алган орнаменталь комплексны тәшкил итә. Болгарларның металлны сәнгатьчә бизәү, сөяк ую сәнгатьләрендә булган лотос, йөрәксыман, көнчыгыш Азия характерындагы пальметта һәм тажлар, интеграль спиральләр, лалә бизәү мотивлары шуларга карый. Орнаментның бу мотивлары Казан татарларының декоратив сәнгатендә: зәркән бизәкләү әйберләрендә, чигүләрдә, каюлы күн аяк киемнәрендә, агач һәм таш ую осталыкларында - аннан соңгы вакытларда да сакланалар.

Болгар металл һәм зәркән сәнгатенең (аның чәчәк аткан вакытындагы эшләрен) чәчәк-үсемлек бизәкләренең үрелгән спираль бөтерләре, яфрак үсентеләре, лалә чәчәкләре, лотос һәм башка бизәк мотивларыннан торган зиннәтле катлаулы композицияләр бизи. Шул бизәкләр кою, уеп (гравировка), төеп (чеканка), басма һәм җепкыр (филигрань) техникаларын кулланып төшерелгәннәр, соляр (кояш, ай, йолдызлар) һәм зооморф мотивлар белән бергә кушылганнар. Мәсәлән, болгар зиннәтле балта сапларының берсендә, медальон астында стильләштерелгән ат сурәте астында кояш дискы һәм ярымай урнаштырылган. Шул ук балтаның йөзе исә, тармакланган "тормыш агачы" яки "дала" чәчәк бәйләме мотивлары белән бизәлгән. Бу сюжетның яхшы теләк белдерү эчтәлеге бик җиңел укыла. Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, анда, Исламга кадәрге болгар сәнгатендә булган "тормыш агачы" һәм "кояш" җанвары булып исәпләнгән ат мотивларының семантикасы сакланган. Яңалык булып бәрәкәт һәм чәчәк ату (уңышка ирешүне) белдергән ярымай семантикасы тора. Моның һәм башка әйберләрне бизәүдә яңа эчтәлекле символлар күренә башлаудан тыш, мөселман сангатенә хас булган келәм (тулысынча бизәү) орнаменталь системасы урын алган. Бизәкләр, арабескаларга охшатып, бизәү әйберенең өслеген тулысынча каплаганнар.

Мөселман сәнгате өчен характерлы булган тоташ орнаментлаштыру принцибы XI гасыр азагы - XII гасыр башы болгар сәнгать предметларында киң таралыш алган. Моны металл матрицалар - рельефлы итеп бизәк төшереп коелган бакыр һәм җиз пластиналар калдыклары дәлилли. Алар белән юка бакыр, көмеш һәм алтын такталарга-пластиналарга күп тапкырлы басма белән бизәкләр тешергәннәр.

(Ахыры 4 нче биттә.)

Идел буенда ислам сәнгатенең башлангыч чоры үзенчәлекләре

(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)

Алар аел, куелмалар, Коръән савытлары, савыт-саба h. б. шуның кебек массакүләм эшләнә торган көнкүреш әйберләренә орнамент төшерү өчен кулланылганнар. Бизәкләр арасында борынгыдан килгән херсонес үрнәкләрен үзләштерүче соңгы эллин традицияләренә карый торган һәм мөселман сәнгате стиленә хас булган арабескалар тибындагы геометрик һәм чәчәк-үсемлек мотивлары кертелгән. Матрицалардагы бизәүнең образлы системасы X-XI гасырлардагы саф зооморф композицияләрдән (мәсәлән, Биләр шәһәре калдыкларын казу эшләре вакытында табылган эт сурәте төшерелгән жиз матрица), XII гасыр ахыры - XIII гасыр башындагы шартлы орнаментальлек һәм шартлы декоративлык тора.

Идел буе болгарлары сәнгатендә зооморф мотивларны сурәтләү реалистик булмаган; ул шартлылык, билгеле бер схемалаштыру һәм форманың бизәү стилизациясе белән аерылып торган. Тере затларны сурәтләгән вакытта кулланылган, болгар мәҗүси мәдәнияте чорларында ук барлыкка килгән бу принциплар мөселман сәнгате чәчәк аткан вакытта, аның сюжетларында мифологик образлылыктан символик, шартлы декоратив образлылыкка әкренләп күчкән вакытта тагын да зуррак үсешкә ирешкәннәр. Мөселман сәнгате метафорик образлылык та кичерә. Мәсәлән, кош мотивы эволюциясен күзәтү бик тә кызыклы. Аның сурәте чынбарлыктан әкренләп кенә күздән югалып, символикка әйләнә бара. Аннан соң инде кош сурәтләре төр аермалыкларын югалта, ул орнамент бизәкләре бәйләнмәләрендәге абстракт "бәхет кошына" әйләнә. Кош, шулай итеп, бәхет һәм мәхәббәт метафорасына әверелә. Шунысын да күрсәтеп китәргә кирәк, сәнгать теле үсеше процессында мөселман сәнгатендә жанварлар һәм кош мотивлары әкренләп чәчәк-үсемлек һәм геометрик мотивлар белән алмашына. Болгар сәнгате спецификасына хас булган "чәчәк стиле", үзенең тәэсирле бизәү системасы белән, болгар халык осталары иҗатында эзлекле рәвештә сакланып калып, күп йөз елларга татар декоратив-гамәли сәнгатенең юнәлешен билгеләгән.

Шулай итеп, Идел буенда мөселман сәнгатенең барлыкка килүе аның бу төбәктә урнашкан сәнгать традицияләренә жайлашуы процессын билгели. Үзәкләштерелгән дәүләтнең монотеистик идеологиясенең бер өлеше булган сәнгать, аның сурәтләү телендә чагылыш тапкан яңа, күпкә югарырак үсеш дәрәҗәсенә ирешә. Исламның идея-эстетик тамырлары Идел буе сәнгатенә, аның халык иҗат спецификасын формалаштыруга, яңа күренешләргә үсеш биргән. Алар, соңыннан, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы сәнгатьләре үсешенә нигез салган һәм татар гомуммилли мәдәниятенең үзәк өлешенә әйләнгән.

Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,
сәнгать фәннәре докторы,
Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының баш фәнни хезмәткәре

Казанда Барудиларны искә алдылар

1 ноябрь көнне ТР Фәннәр академиясе “Бертуган Барудиларның татар мәгърифәтчелегенә керткән өлеше” дип аталган төбәк фәнни-гамәли конференция уздырды. Жыен күренекле татар педагоглары һәм мәгърифәтчеләре Галимжан Барудиның тууына − 155 ел, Салихжан Барудиның тууына 150 ел тулуга багышланды. Конференцияне Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм аның Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге оештырды.

Жыен эшендә фәнни кызыксынулары тәрбия һәм белем бирүнең теория-методология, педагогика һәм татар педагогик фикере тарихы, шулай ук дини белем бирү проблемалары белән бәйләнешле галимнәр, аспирантлар, югары уку йортлары студентлары катнашты.

Дәрестән дә, Барудиларның исеме һәм эшчәнлеге совет чорында уңай яктан телгә алынмады диярлек. Бары тик узган гасырның 80 нче елларында, ягъни тарихка объектив бәя биреләе башлагач кына, Баруди кебек шәхесләрнең эшчәнлеген яктыртуда гаделлек ягы көчәйде.

Әчке Русия татарларының иң мәшһүр һәм атаклы мәдрәсәләреннән берсе, асылда, милли университет вазифасын үтәгән «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»не аның нигез ташларын салучысы, житәкчесе, мөдәррисе Галимжан Галиев-Баруди исеменнән башка күз алдына китерүе мөмкин түгел. Ул XIX йөз ахырларында ук күренекле мәгърифәтче, дин белгече һәм реформаторы, философ, педагог буларак, дистәләрчә китаплар язып бастыра. Бу олпат шәхеснең абруе XIX йөз ахыры – XX йөз башында гаять зур була. Рус мәмләкәтенең уннарча төбәкләрендә нәшер ителгән татарча газета-журналларда аның исеме бернинди аңлатмаларсыз «Галимжан хәзрәт» дип кенә бирелгән. Үз чорында мондый популярлык һәм абруйга бары берничә генә шәхес (Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин, И.Гаспринский h. б.) ия була. Рәсми русча документларда мәдрәсәнең исеме еш кына «Мөхәммәдия» дип түгел, бәлки нигезләүчесе һәм житәкчесенә нисбәттән «Галеевское медресе» дип йөртелә..

Г.Баруди

С.Баруди

Ачылган вакытында «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» башка иске төрдәге уку йортларыннан берни белән дә аерылмый диярлек, фәкать гарәп теле һәм дин дәресләре генә яңа баскычка куела. Ләкин мәшһүр уку йортларында гыйлем алган һәм сәфәрләрендә бай тәжрибә туплаган Галимжан хәзрәт, реформа ясамый торып, милли мәгариф эшен алга жибәрү мөмкин түгеллеген яхшы аңлый. Моның өчен башта башлангыч сыйныфларны, аннары шуның нигезендә урта һәм югары классларны үзгәртеп кору кирәк дип табыла. Шул ихтыяжның нәтижәсе буларак, 1891 елда «Мөхәммәдия»дә ысуле жәдидә, ягъни Европа мәгърифәте, Шәрык казанышларына нигезләнгән яңа метод белән укыту гамәлгә кертелә.

Кыскасы, Барудилар тырышлыгы белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе XX йөз башларында һәр жәһәттән уңышлар казана.

Татар милләте тарихында, бигрәк тә аның мәдәниятә һәм динифәлсәфи карашлары өлкәләрендә, якты эз калдырган бу олуг затларны без хаклы горурлык хисе белән искә алырга һәм аларның күпкырлы эшчәнлеген фәнни нигездә өйрәнергә тиешбез.

Нияз САБИРЖАНОВ

ТОРМЫШ – иң катлаулы мәдрәсә

(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)

итәргә тырышучылар бар. Менә аларны "нетрадицион ислам" вәкилләре дип атап буладыр инде.

- Димәк, ислам турында жәмәгатьчелек фикерен формалаштыруда мөселманнарның үзара мөнәсәбәте дә зур роль уйный?

- Әлбәттә, шулай. Ислам дине үсеш кичерүен, кешеләрнең күңеленә яхшы, файдалы тәгълимат буларак керүен теләсәк, дин тотучы мөселманнарның бердәм, дустату булуы мөһим. Ә моның нигезе - бер мәзһәбтә, бер нияттә булу, житәкчеләргә итагать итү. Икенчедән, һәр мөселман диннең көзгесе булуын онытмаска һәм динебез буенча яшәүче кешегә хас булырга тиешле күркәм әхлак сыйфатларын үзендә булдырырга тиештер, дип уйлыйм.

- Бүгенге катлаулы заманда әдәп-әхлак кагыйдәләрен белү, алар буенча яшәү барчабызга да комачау итмәс иде. Күркәм әхлак сыйфатларыннан кайсыларын аерым билгеләп үтәр идегез?

- Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) бер хәдисендә: "Иманның ярты сабырлык, икенче ярты шөкер итү", - дип әйтелә. Чыннан да, безгә бүген сабырлык һәм шөкер итү сыйфатлары житенкерәми. Бүген күп кешеләр шәхси уңышларын, гомумән, тормыштагы бәхетен акча, матди байлык булдыруга бәйли, янәсе, никадәр күбрәк юнәтәм, шулкадәр бәхетлерәк булам. Әмма шунысы мөһим: күпме генә байлык-мал тупласаң да, Аллаһы Тәгалә бәрәкәт бирмәсә, шул байлыкның файдасы бик аз булачак. Ә Аллаһ бәрәкәтле иткән әз генә малның файдасы күп булырга мөмкин. Уйлап карасаң, Аллаһы Тәгалә безгә ничәмә-ничә нигъмәтен бүләк итеп бирә: су, һава, сәламәтлек, балалар h. б. Бер генә күзнең күрүен акчалата бәяләп карагыз әле? Ризык тәмен тою, йокы, акыл, тумыштан бирелгән сәләт - болары ничә сум тора? Чыннан да, без бернинди акчага да сатып алып булмый торган нигъмәтләргә ия, әмма аның кадерен белмибез, тиешенчә шөкер итмибез. Ә галимнәребез аңлатканча, шөкер итү мал-нигъмәтләрне арттыра, сабыр итү исә Аллаһка якынайта.

- Безгә бик кирәкле, файдалы сыйфатлар турында әйтеп киттегез. Ә нинди сыйфатлар кешегә зур зыян китерә?

- Әлбәттә, сабырсызлык. Аннары күп кешегә жаваплылык хисе булмау, дөньяга артык кызыгу, мин-минлек сыйфатлары да шактый зыян китерә, дип уйлыйм. Үзеңне башкалардан өстен кую, үз-үзенә соклану, сүздә тормау кебек тискәре сыйфатлар да хәзер киң таралган. Ә инде төп кимчелек - ул күпләрнең күңел күзе белән күрә алмавы.

- Бүген кешенең маңгай күзе генә күрә торган заманда аның күңел күзен ачар өчен дин белеме кирәктер инде? Мәдрәсәгездә уку елы ничегрәк башланып китте, укырга килүчеләр күпме?

- Быел без 15 нче уку елын башлап жибәрдек. Узган уку елында мәдрәсәбезне 128 кеше тәмамлаган иде, быел 160 лап кешене укырга кабул иттек. Олылар балаларга караганда күбрәк. Яшьләр бик күп, ә менә пенсия яшендәге абыйлар, шул яшьтәге апалар белән чагыштырганда азрак. Шул хакта сүз чыккач, миңа берәү: "Бездә ирләр пенсиягә кадәр яшәмиләр, күбесе үлеп бетте инде", - ди. Мин әйтәм: "Нишләп үлеп бетсеннәр, урамда күренәләр ич, хастаханәдә дә күп йөри алар. Әмма, Жәлил хәзрәт әйткәнчә, сәламәтлекне мәчет-мәдрәсә юлында эзләргә кирәк, ә намаз - ул бик күп авыруларны булдырмый калырга ярдәм итә".

Тулаем алганда, уку елы әйбәт кенә башланып китте. Шунысы сөендерә: бөтен уңайлыклары булган зур, бик матур бинабыз бар, халык бик ошатып укып йөри, барыбызга да шөкер итеп тырышасы гына.

- Гәжит укучыларга теләк-нәсыйхәтегезне житкерсәгез иде.

- Әгәр юл йөрү кагыйдәләрен белмәгән кеше машинаны үзе идарә итеп кузгалып китсә, нәтижәсе бик аяныч булырга мөмкин. Бүген исә бик күп кеше кирәкле канун-кагыйдәләрне өйрәнмичә, "тормыш" дигән машинада бара, кайберләре хәтта кайда "газ", кайда "тормоз" булганын да чамаламый. Моны дини гыйлемнең кирәклегенә ишарә итеп әйтүем.

Безнең тормышыбыз ул үзенә күрә бер сынау, аны белем-сабак йорты белән дә чагыштырып була. Әйе, тормыш ул - иң катлаулы мәдрәсә. Без көн саен нәрсәдер эшлибез, нәрсәгәдер омтылабыз, шулай итеп, Аллаһ каршында көн саен имтихан тотабыз. Үземә яхшы булсын дип кемгәдер авырлык китерсәң, нинди дә булса проблемаңны хәл иткәндә хәрамга керсәң, ахирәт "зачётка"сына икеле куялар инде. Ә Кыямәт көненде "Госэкзамен" булачак. Шуннан соң "зачётканы", ягъни гамәл дәфтәреңне тоттыралар да, йә жәннәткә, йә жәһәннәмгә билгелиләр. Шуңа күрә без барыбыз да "тормыш" дигән мәдрәсәдә "укучы" шәкертләр. Имтиханнарны яхшырак биреп барыр өчен һәм "Госэкзамен"га әзерләнү өчен мәдрәсәбездә белем алырга чакырам.

Әңгәмәне Г.МИҢНЕХАНОВА үткәрде

Казанда намаз вакытлары

Көн исеме	Дата	Иртәнге намаз	Кояш чыгу	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
Шимбә	3.11.12	6:25	7:55	13:02	15:40	16:59	18:29
Якшәмбе	4.11.12	6:27	7:57	13:02	15:39	16:57	18:27
Дүшәмбе	5.11.12	6:29	7:59	13:02	15:37	16:55	18:25
Сишәмбе	6.11.12	6:31	8:01	13:02	15:36	16:53	18:23
Чәршәмбе	7.11.12	6:33	8:03	13:02	15:35	16:51	18:21
Пәнҗешәмбе	8.11.12	6:35	8:05	13:02	15:33	16:49	18:19
Жомга	9.11.12	6:37	8:07	13:02	15:32	16:47	18:17
Шимбә	10.11.12	6:39	8:09	13:02	15:31	16:45	18:15

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 18 (161) чыгарылыш.
Гамәлгә куючы һәм нәшир: Үзәкләшкән дини оешма − Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
Баш мөхәррир: Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
Мөхәррир: Нияз САБИРЖАНОВ.
Дизайнер: Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
Тираж: 5000 данә. **Заказ:** 9423.

Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.
Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
График буенча бу санга 1 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.
Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.
Электрон адрес: niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы − "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!